| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МАКУЛОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>МАКЫЛ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.09.2017 51

с. Русское Макулово

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан ИП В.А. Чикаловка Макыл авыл җирлегенең торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү буенча транспорт чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Россия Федерациясе Федераль законының 06.10.2003 ел 131 карарының 15 ст., 1 п., 18 п.п. нигезендә, авыл җирлеге составына керүче торак пунктларны сәүдә хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. ИП В.А. Чикаловка Макыл авыл җирлегенең торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү буенча транспорт чыгымнары өлешен каплауга Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе: Л.Р. Цветкова

Югары Ослан муниципаль

районы Макыл авыл
җирлеге башкарма
комитетының
21.09.2017 ел № 50
карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан ИП В.А. Чикаловка Макыл авыл җирлегенең торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү буенча транспорт чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмә.

1. Гомуми нигезләмәләр

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан Макыл авыл җирлегенең торак пунктларына беренче чиратта кирәк-яраклар китерү буенча транспорт чыгымнарының бер өлешен каплауга ИП В.А. Чикаловка субсидия бирүне регламентлаштыра.

1.1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты субсидия бирү буенча Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджеты акчаларын баш бүлүче булып тора.

1.2. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр алучы - ИП Чикалов В.А.

1.3. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетының баш бүлүчесе һәм Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр алучы арасындагы мөнәсәбәтләр әлеге Нигезләмә белән җайга салына.

1.4. Баш бүлүче:

1.4.1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджетында каралган яки Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджетын үтәү барышында бирелгән исәп-хисаплар буенча өстәмә бүлеп бирелгән акчалар хисабына субсидияләр алучыга субсидияләр бирүне гамәлгә ашыра.

1.4.2. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджетыннан субсидия алучыларның максатчан файдалануын тикшереп тора.

1.5. Субсидияләр алучы:

1.5.1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджетыннан максатчан файдалануны тәэмин итә.

1.5.2. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджеты акчаларын гамәлдәге законнар нигезендә максатчан файдаланмаган өчен җаваплы.

2. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

2.1. Субсидияләр Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан төзелгән килешү нигезендә бирелә.

3. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп тору

3.1. Бүлеп бирелгән субсидияләрне максатчан файдалануны Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты тикшереп тора.

Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе: Л.Р. Цветкова